РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 05 » 03 2025 ел №207

2025 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 08 декабрендәге 257-ФЗ санлы Федераль закон, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 03 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 санлы «Региональ яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яки вакытлыча туктату тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, уңай булмаган табигать-климат шартлары барлыкка килгән чорда, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының конструктив элементларының сәләтен киметүгә юл куймау максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Түбәндәге чорда кертергә:

2025 елның 1 апреленнән 30 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында (алга таба – җирле әһәмияттәге автомобиль юллары) йөк белән яисә йөксез транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне, автомобиль юллары буйлап йөрүнең рөхсәт ителгән чик күләмен транспорт чарасы

күчәренә төшкән йөкләнешнең 6 тоннадан арттырмауны (алга таба – язгы чорда хәрәкәтне вакытлыча чикләү);

2025 елның 20 маеннан 31 августына кадәр «Татарстан Республикасы Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсе» Федераль дәүләт бюджет учреждениесе бирә торган мәгълүматлар нигезендә, көндезге һава температурасы 32 °тан югарырак булганда, җирле әһәмияттәге асфальт-бетон өслекле автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташучы транспорт чаралары өчен вакытлыча чикләүне (алга таба – җәйге чорда хәрәкәтне вакытлыча чикләү).

Хәрәкәтне вакытлыча чикләү түбәндәге чорда гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

язгы чорда - Россия Федерациясе Юл хәрәкәте кагыйдәләре нигезендә «Төзекләндерү» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан 3.12 «Транспорт чарасы күчәренә туры килә торган массаны чикләү» юл билгеләре кую юлы белән;

җәйге чорда «Татарстан Республикасы Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсе» Федераль дәүләт бюджет учреждениесе мәгълүматлары буенча, көндезге һава температурасы 32 °тан югарырак булганда, 10.00 сәгатьтән 22.00 сәгатькә кадәр – «Төзекләндерү» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан «Хәрәкәтнең аерым шартлары» графасына җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча авыр йөк ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары хәрәкәтенә махсус рөхсәт кертү юлы белән, күчәрләренә яки күчәрләр төркеменә йөкләнеш, Россия Федерациясе территориясендә билгеләнгән төп йөкләнештән артып киткән транспорт чаралары хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү юлы белән түбәндәге эчтәлекле язма язарга: «Авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары хәрәкәте, һава температурасы 32 °тан артык булганда тыела һәм 22.00 сәгатьтән 10.00 сәгатькә кадәр рөхсәт ителә».

3. «Татарстан Республикасы гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитетына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Ютазы районы буенча юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе бүлегенә, ««Төзекләндерү» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә җәйге чорда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә көндезге вакытта урнашкан һәм фаразлана торган һава температурасы турында хәбәр итәргә тәкъдим итәргә.

4. Хәрәкәтне вакытлыча чикләү түбәндәгеләргә кагылмый:

- «Халыкара автомобиль ташуларны гамәлгә ашыруны дәүләт контроле турында һәм аларны үтәү тәртибен бозган өчен җаваплылык турында»гы 1998 елның 24 июлендәге 127-ФЗ санлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла торган халыкара йөкләр ташуга;

- пассажирлар ташу автобуслары, шул исәптән халыкара автобуслары;

- азык-төлек продуктларын, хайваннарны, дару препаратларын, орлык фондын, ашламалар, почта һәм почта йөкләрен (әлеге пунктта күрсәтелмәгән йөкләр белән бергә ташудан тыш) ташу;

- 16 тоннага кадәр йөк сыйдырышлы транспорт чараларына, ягулык (бензин, дизель ягулыгы, суднолар ягулыгы, реактив двигательләр өчен ягулык, топ мазут, газ ягулыгы) ташый торган җайланмаларга;

- стихияле бәла-казаларның яисә башка гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бетерү өчен кирәкле йөкләрне ташуга;

- авария-торгызу һәм ремонт эшләрен башкарганда кулланыла торган юлтөзелеш һәм юл-эксплуатацияләү техникасын һәм материалларны транспортировкалауны гамәлгә ашыручы транспорт чараларына;

- федераль законда хәрби хезмәт каралган федераль башкарма хакимият органнарының транспорт чараларына;

- каты коммуналь көнкүреш калдыкларын җыю һәм транспортировкалау өчен кулланыла торган махсуслаштырылган транспорт чараларына (чүп ташый торган транспортка);

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын агымдагы карап тотуны тәэмин итә торган юл-төзелеш оешмаларының транспорт чараларына.

5. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә (оештырырга):

- Россия Федерациясе законнары нигезендә, аларның күчәренә йөкләнеш әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән иң чик мөмкин булган йөкләнештән артып китсә, йөк төягән яисә йөксез транспорт чараларының җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап хәрәкәтенә махсус рөхсәтләрне үз вакытында бирүне;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук мондый чикләүләрнең сәбәпләре һәм сроклары турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша үз вакытында хәбәр итүне.

6. «Ютазы муниципаль районы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтенә 2024 елда вакытлыча чикләүләр кертү турында»гы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 25 мартындагы 329 санлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Р.Р. Малова
2-42-07